**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 24 октябрендәге 3701 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 19 маендагы 1555 номерлы**
**«Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!»**
**шигъри конкурсын үткәрү турында»гы карарына**
**үзгәреш кертү хакында**

Казан шәһәре бюджеты акчаларын нәтиҗәле файдалану максатыннан, «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсы нәтиҗәләрен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 19 маендагы 1555 номерлы «Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрү турында»гы карарына, 4 пунктны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә (вазифалар башкаручы Е.Н.Әхмәтшина) Казанга багышланган «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигъри конкурсын үткәрү белән бәйле чыгымнарны 2025 елда 2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программа чараларын башкаруга бюджет исемлегендә каралган акчалар кысаларында гамәлгә ашырырга».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**